## СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУ ТУРЫНДА

Сүзлектә терминнар алфавит тәртибендә урнаштырылды:

**баро’метр** *м* барометр

**барометр-анеро’ид** *м* барометр-анероид

**баро’метр-высотоме’р** *м* биеклегүлчәгеч барометр

**барометри’ческий** барометрик

Күп кенә баш сүздән соң алфавитлы-оялы система нигезендә шул термин белән ясалган терминологик сүзтезмәләр китерелде. Төп термин ояда һәрвакыт беренче урынга куелды һәм тильда (~) белән алыштырылды:

**расшире’ние** *с* киңәю

**~ терми’ческое** термик киңәю

Төп сүзе беренче урында тормаган сүзтезмәләр төп сүздән соң нокталы өтер белән аерып бирелде, мәсәлән:

**ландша’фт** *м* ландшафт, **лу’нный** ~ Ай ландшафты

Кайбер терминнарга аңлатмалар бирү кирәк табылды. Алар түгәрәк җәяләр эчендә курсив белән бирелде, мәсәлән:

**одо’метр** *м* (*счётчик оборотов колеса*) одометр (*тәгәрмәч әйләнешләрен санагыч*)

Терминның факультатив өлеше шулай ук түгәрәк җәяләр эчендә, ләкин туры шрифт белән бирелде, мәсәлән:

**след** *м* эз

**~ спутника (на аэросни’мке)** (аэросурәттә) иярченнең эзе

Синонимик вариантлар квадрат җәяләр эчендә урнаштырылды, мәсәлән:

**закрепле’ние** *с* ныгыту, беркетү

**~ грани’ц, администрати’вное [юриди’ческое]** чикләрне административ [юридик] яктан ныгыту

Синонимнар – өтер, ераграк мәгънәләр – нокталы өтер, төрле мәгънәләр цифрлар белән күрсәтелде6

**обозначе’ние** *с* билгеләү, тамгалау; билге

**размеще’ние** *с* **1.** урнаштыру **2.** тоташтырма